**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет Пестречинского муниципального района**
422770, с. Пестрецы, ул. Советская, 18

**Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты**
422770, Питрәч авылы, Советурамы, 18

тел. +7 (84367) 3-02-02факс: (84367) 3-02-01 E-mail: pitriash@tatar.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ

# КАРАР

«16» апреля, 2021 ел

№ 258

«Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары бирү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 02 мартындагы 317 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 05 декабрендәге 999 номерлы карары нигезендә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 05 декабрендәге 999 номерлы карары нигезендә гаиләнең җан башына туры китерү рәвешендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 10 сентябрендәге 625 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетының 2017 елның 02 мартындагы 317 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Балага айлык пособие билгеләгәндә гаиләнең уртача җан башына кереме, бала өчен айлык пособие билгеләү турында гариза бирү ае алдыннан алты календарь айга кадәрге соңгы 12 календарь айда гаилә әгъзаларының керемнәре суммасыннан чыгып исәпләнә»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында http://www.-pestreci.tatarstan.ru һәм «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.С. Шәйхесламовка йөкләргә.

Муниципаль район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.В. Хәбибуллин

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ИНН 1633605397